
# Ислам нуры

№ 2 (654) 29 гыйнвар, 2018 ел (1439, Җөмәдел-әүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

12+


# “Тәҗвидле Коръән” – күңел бизәге




“Ислам нуры” дини-эшмәкәрлек үзәге белән Татарстан халкы гына түгел, Рәсәйнең бик күп төбәгендә яшәүчеләр яхшы таныш. Дини эчтәлектәге китаплар белән бергә, әдәби әсәрләр дә, “Ислам нуры” газетасы да, башка төрле басма продукция дә инде ничәмә-ничә еллар дәвамында биредә “дөнья күреп”, халыкка таралып килә. Үз эшенең остасы булган егет-кызлардан менә дигән коллектив тупланган, типография заманча җиһазлар белән баетылган, биредә басылган китапларның сыйфаты күпләрне көнләштерерлек. Берничә данәдән башлап, әллә ничә меңнәрчә тираж белән бастыру мөмкинлеге дә күзне кызыктырырлык.

Шушы көннәрдә генә биредә барлык мөселманнар өчен изге саналган Коръән китабының өр-яңа басмасы — “Тәҗвидле Коръән” табадан төште. Аның инициаторы да, тормышка ашыручысы да — үзәкнең генераль директоры, үзе хаҗи булган Иршат Гыйльметдин улы Шәйхаттаров. Яңа басманың үзенчәлеге шунда — ул гарәп шрифтында да, транскрипциядә кириллица белән дә бирелгән, аерым төс белән тамгаланган хәрефләрне дөрес укуны, авазларның дөрес әйтелешен күрсәткән тәҗвид өлеше дә бар, Ногмани тәфсиренә таянып, татарча тәрҗемәсе дә урын алган. Китап инде “Ислам нуры” кибетенә дә, мәчетләр янындагы кибетләргә дә сатуга чыгарга өлгерде.



23 январь көнне “Ислам нуры” дини-эшмәкәрлек үзәгендә “Тәҗвидле Коръән” китабы Чаллы шәһәр музее хезмәткәрләренә, “Шәһри Чаллы”, “Ислам нуры” газетасы вәкилләре игътибарына тәкъдим ителде. Аларга Коръән китабының басылу тарихы турында сөйләделәр, ничек, ни рәвешле дөньяга чыгуы типография буйлап экскурсия рәвешендә оештырылды. “Без Иршат хаҗи белән инде күп еллар аралашабыз, эшчәнлегенә сокланып туймаслык”, — диде музейның өлкән фәнни хезмәткәре Билял Канеев, директорга музей җитәкчелегенең Рәхмәт хатын тапшырып. Музей фондларының баш саклаучысы Н.А. Микрюкова да җылы сүзләрен җиткерде. Кунаклар үзләре дә буш кул белән китмәде: Коръән китабы музей фондына бүләк итеп бирелде.



“Шәһри Чаллы” газетасы корреспонденты, шагыйрә Лилия Фәттахова: “Мин Чаллыга күптән түгел генә күчеп килдем, яшермим, мондый типография барлыгын белми идем”, — дип, биредә басылган китапларның сыйфатына соклануын белдерде.

“Дөньяны яуларга омтылма, аның гыйлемен яуларга омтыл”, — ди татар халык мәкале. Чын гыйлемнең кулдагы телефонда, планшетта, яки телевизор экранында түгел, нәкъ менә китапларда икәнен аңлы кешегә төшендереп тору кирәкми. Кеше күңелендә зыялылык, әхлак, матурлык тәрбияләүче әдәби китаплар мең, миллион төрле булса, яшәүнең бөтен сере, мәгънәсе тупланган, ахирәттә дә терәк булучы кагыйдәләрне, гыйлемне төшендергән китап бирәү генә, ул — гасырлар буе буыннан-буынга тапшырылып килгән Коръән китабы. Һәр мөселман кешесенең күңел бизәге ул...

## Ерак араны якын итеп...



Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин җитәкчелегендәге делегация Казахстанның Актүбә шәһәренә сәфәр кылды. Төп максат — шәһәрнең Җәмигъ мәчете белән танышу иде, чөнки аның һәм Чаллыда төзелеп килүче Җәмигъ мәчетенең архитекторы һәм проектлаучылар төркеме бер үк. “Без мәчетнең һәр өлеше белән җентекләп танышып чыктык. Максатыбыз — күргән уңай якларны искә алып, үз проектыбызны тагын да камилләштерү иде. Актүбә мәчете мәхәлләсе тормышы белән дә якыннан таныштык”, — дип үз тәэсирләре белән уртаклашты Әлфәс хәзрәт.

**Рәсемдә:** Актүбә шәһәрендә.

## Без — татарлар

Республика мәчетләрендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте оештырган “Без — татарлар” татар теле һәм ислам дине нигезләре курслары эшли башлады. Әлмәт, Яшел Үзән, Чаллы, Түбән Кама, Алабуга мөхтәсибәтләренең үзәк мәчетләре һәм Казанның “Кабан арты”, “Гаилә”, “Тынычлык”, “Әнилә р”, “Ярдәм” мәчетләрендә курсларга язылучыларның саны байтакка җитте. Татар теле курслары 2 февральдән ачылачак. Белем бирү өчен “Хозур” нәшриятында басылган “Татар теле. Башлап өйрәнүчеләр өчен” дәреслеге әзерләнде. Дәресләрне татар филологлары, татар теле һәм ислам дине нигезләре мөгаллимнәре алып барачак.

Чаллы мөхтәсибәтенең “Ак мәчет”ендә курслар дүшәмбе, чәршәмбе, җомга көннәрендә кичке җидедән тугызга кадәр үткәрелә.

# Фиргавен кавеменә килгән җәзалар

**Әссәламугаләйкум, газиз дин кардәшләрем!**

**Аллаһы Тәгалә җир йөзендә билгеле бер тәртип, кагыйдәләр урнаштырды һәм беркем дә аларны боза алмый. Бар нәрсә шушы кануннарга буйсына. Һәм шул кагыйдәләрнең берсе — Аллаһы Тәгалә хакыйкать барып ирешмәгән кешене җәзага тартмый.**

Аллаһы Тәгалә әйтә: "Пәйгамбәр җибәреп, шәригать хөкемнәрен өйрәтмичә, һичбер кавемне газаб кылыр булмадык", — ди. («Исра» сүрәсе, 15нче аять). Ягъни, без, пәйгамбәр җибәреп, ул халыкка шәригать хөкемнәрен өйрәткәнчегә кадәр һичбер кавемне газаб кылмадык, ди. Аллаһы Тәгалә безне бар кылганнан соң ялгызыбызны гына ташлап калдырмады, ә бәлки иксез-чиксез нигъмәтләрен, ризыкларын бирде. Җир йөзен без яши алырлык итеп яратты. Кешелекне туры юлга күндерү өчен илчеләрен, пәйгамбәрләрен җибәрде. Ахирәт көнне хисап кылынган вакытта адәм балалары Аллаһ Тәгалә каршында аклана алмаячаклар, чөнки Раббыбыз безгә кирәк булган бар нәрсәне дә бирде. Әгәр кешегә могҗизалар, ачык дәлилләр ирешеп тә, ул хакыйкатьтән читләшә икән, Аллаһның җәзасы котылгысыз булыр!!!

Фиргәвен һәм аның кавеменә хакыйкать барып ирешә. Алар Мисыр шәһәренең иң зур мәйданында Муса галәйһи сәламнең пәйгамбәрлеген һәм аның Аллаһның илчесе икәнен дәлилләүче могҗизалар күрделәр. (Фиргавеннең бертуганының улы аларны, иманга килмәгән очракта, Аллаһның каты җәзасы булачагы белән куркытуы турында язып чыккан идек инде.) Ләкин бу Фиргәвенгә һәм аның кавеменә берничек тәэсир итми, һәм алар үзләренең имансызлыкларында каты торалар. Шуннан Муса галәйһи сәлам Фиргавеннән үзе һәм халкы өчен Мисыр җирләреннән күчеп китәргә рөхсәт сорады. Чөнки аның халкына мондый җәмгыятьтә Аллаһка гыйбадәт кылу бик кыен иде. Алар Мисыр халкы өчен кол дәрәҗәсендә — хокуксыз, кимсетелгән хәлдә иделәр.

Ләкин Фиргавеннең кансызлык һәм ачу белән тулы имансыз йөрәге Муса галәйһи сәламне һәм аның кавемен иреккә җибәрүдән баш тарты. Менә шунда Аллаһның җәзасы башлана!

**Беренче җәза. Аллаһы Сөбеханәһу Тәгалә аларның җирләренә корылык җибәрә.** Күктән бер тамчы яңгыр төшми, җир кибә. Уңыш юк. Аллаһы Тәгалә бу хакта болай ди: "Тәхкыйк Фиргавен кавемен ачлык белән вә бакча җимешләрен уңышсыз итү белән бәлаләндердек, вәгазьләнеп иман китерсеннәр өчен". (Әгъраф сүрәсе, 130).

Ләкин бу аларга тәэсир итмәде, ә тагын да көчле ачуларын гына чыгарды һәм алар бу хәлдә Муса галәйһи сәламне гаепли башладылар.

"Әгәр аларга шатлык, байлык килсә: "Бу безгә тиешле, үзебезнең яхшылыгыбыздан килде", әгәр яманлык ирешсә: "Бу яманлык Муса белән аның иярченнәреннән", — дип шомланырлар. Хакыйкатьтә, аларның шомланулары Аллаһы хозурында, әмма аларга ирешкән яманлык үзләренең кәсебе өчен Аллаһыдан ирешә, ләкин күбесе Аллаһыдан ирешә дип белмәсләр". (Әгъраф сүрәсе, 131)

Шуннан Аллаһ Тәгалә аларга чираттагы җәзасын җибәрә.

**Икенче җәза — кан белән җәзалау.** Нил елгасындагы һәм барча сулыклардагы, хәтта савытлардагы бөтен булган су канга әверелә, фәкать яһүдиләрдәге су гына чиста кала. (Әмма Фиргавен кавеме ул чиста суны талап алса, хәтта ул су да канга әверелгән). Мисырлылар бары тик яһүдиләрдән сатып алган суны гына эчә алган. Шулай итеп, яһүдиләр баеган. Риваятьләрдә килгәнчә, Фиргәвеннең сихерчеләре яһүдиләрдән су сатып алып, аны сихерле башлаганнар, һәм, ниһаять, алар теләкләренә ирешәләр — су канга әйләнә. Шуннан соң Фиргәвен бу җәза Аллаһтан түгел, ә бары тик яһүдиләрнең сихере генә дип уйлый, һәм яһүдиләрне иреккә җибәрми.

Карагыз, никадәр каты булырга мөмкин кешенең йөрәге! Һәм Аллаһның аятьләрен ишетә торып та, Аның боерыкларын үтәмәүче безнең йөрәкләр дә никадәр каты!

**Аннары Аллаһы Тәгалә өченче җәзасын җибәрә — ул да булса, гөберле бака һәлакәте.** Гөберле бакалар Мисыр җирен тулаем биләп алалар. Кая карама, шунда бака була: тәлинкәләрдә, табак-савыт, урын-җирләрендә. Кеше өчен җирәнгеч булган бу җанвар белән барлык Мисыр җире тулган була. Мисыр сихерчеләре янә эшләренә керешә, әмма аларның сихерләре бу җәзага каршы көчсез булуын Фиргәвенгә ирештерәләр. Шуннан Фиргавен Муса галәйһи сәламгә болай ди: "Аларга Аллаһының газабы килгәндә әйттеләр: "Ий Муса! Безнең өчен Раббыңа дога кыл, Ул сиңа дога кыл дип әмер иткәне өчен! Әгәр безнең өстебездәге газабны җибәрә алсаң, әлбәттә, сиңа иман китербез һәм Ягъкуб балаларын да синең белән, әлбәттә, җибәрербез". Муса догасы аркасында алардан газабны алсак, киләсе газаб вакытында, шул вакытта алар гаһедләрен сындыралар — сүзләрендә тормыйлар. (7.134-135).

Гөберле бакалар юкка чыкканнан соң Фиргавен үзенең вәгъдәсеннән баш тарта. Безнең тормышта да шулай түгелме әллә? Һәрберебезнең авыр хәлдә калганы бар! Кемнеңдер күз алдында баласы югары температура белән үлем хәлендә яткан, һәм беркем дә аңа ярдәм итә алмаган, шул кеше Аллаһтан баласына шифа сораган: "Әгәр дә балам терелсә, мин үзгәрермен", — дип вәгъдә иткән. Йә кемгәдер, ярлылыгы сәбәпле, калдык ипи кисәкләрен җыярга туры килгән һәм ул Аллаһтан тук тормыш сораган. Кемдер Аллаһтан үзенең эшендә, кәсебендә, укуында уңышлар сораган һәм үзгәрермен дип вәгъдә иткән! Кайда хәзер синең вәгъдәләрең?! Ач вакытында Аллаһ сине туендырганын, киемең булмаганда Аллаһ сине киендергәнен оныттыңмы әллә син? Син ялгызың җылылыкка тилмергән вакытта, Аллаһ сиңа җылылык биргәнен оныттыңмы? Ничек тиз онытабыз!!!

Шулчак Аллаһы Тәгалә аларга чираттагы җәзасын җибәрә.

***(Вәгазьнең дәвамы киләсе санда)***

**Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев,**
**Чаллының "Тәүбә" мәчете**
**имам-хатыйбы.**

## МИНЕМ ФИКЕР



**Рәис хәзрәт Әхмәтов, "Сөембикә" мәчете имам-хатыйбы**:

Тел, тел, дибез, әгәр аны үзебез сакламасак, кем килеп саклар дисез? Чеп-чи татар әбиләренең үз оныклары белән урысча сөйләшкәнен ишетеп, җан әрни... Мин үзем балаларга кичен гел татарча әкият сөйли торган идем. Берзаман әкият бетеп китте. Аптырагач, берсенең башын, икенчесенең ахырын алып, үземчә "яңартып" сөйләргә тотындым... Туган телне саклауга һәркем үзеннән бер генә тамчы өлеш кертсен иде дә соң!.. Бер риваятьне искә төшерәсем килә. Бервакыт урманга ут капкан, янына якын килмәле түгел, ялкын чорнап алган. Кечкенә генә бер кошчык томшыгы белән су ташырга тотынган. Башкалар, моны күреп: "Син нәрсә, әллә шулай итеп янгынны сүндерә алырмын дип уйлыйсыңмы?" – диләр икән. "Юк, уйламыйм, тик үземнән нәни генә булса да өлеш кертәсем килә! Бу бит минем урманым, монда минем балаларым үсте!" – ди икән кошчык...

# Кем нәрсәгә ия – шуның белән бүлешә

Ихлас гыйбадәт кылучы бер әдәпле мөселман яңа йорт сатып алып, шунда күченә. Йорт янында шактый зур алма бакчасы була. Бакча киртәсе артында иске генә өйдә холыксыз бер кеше яши иде. Яңа күршесеннән көнләшеп, ул көн саен аңа нинди дә булса начарлык эшләргә тырыша.

Көннәрдән бер көнне мөселман, иртәнге намазга мәчеткә барам дип өеннән чыккач, болдырында пычрак юынтык су чиләген күрә (бу аның динсез күршесенең чираттагы "күчтәнәче" була). Мәчеттән кайткач, мөселман пычрак суны түгеп, чиләкне яхшылап юа да, шунда иң зур, иң матур хуш исле алмалар тутырып, күршесенә китә. Аны тәрәзәдән күргәч, холыксыз кеше: "Тәки теңкәсенә тидем бит моның – ызгышырга керә бу!" – дип шатланып куя. Ишеген ачкач, ул яңа күршесе кулында алма тулы чиләкне күрә һәм аптырап: "Бу... нәрсә?.." – дип сорый. "Күрмисеңмени, алма", – дип җавап бирә күршесе, һәм шаяртыбрак күзен кысып: "Кем нәрсәгә ия – шуның белән бүлешә", – дип өстәп куя.

**Ришат хәзрәт Курамшин,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

## СОРАУ-ҖАВАП

**Мөхтәрәм "Ислам нуры" редакциясе!**

**Түбәндәге сорауларга җавап бирсәгез, бик рәхмәтле булыр идем.**

**Хәзерге вакытта балаларны уллыкка алу киң таралган һәм ул хуплана торган нәрсә. Ә шәригатьтә ул тыелган. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: "...вә дәхи уллыкка алган асрау ир балаларны сезгә хакыйкый угыл кылмады..." Мәсәлән, бер ир кеше балалы хатынга өйләнде ди, хатын аныкы була, ә бала аныкы түгел. Ул аңа эти дип әйтә алмый, ә ир улым дип әйтә алмый. Кайвакытта бала тудыру йортыннан алалар. Бу очракта да шулаймы? Күпчелек вакытта белгертмиләр бит ул аларныкы түгел икәнен. Димәк, бу инде дөрес түгел.**

**Икенче соравым. Зәкәт, гошер сәдакаларын шәһәрдә яшәүче балаларыңа бирү дөресме? Мәсәлән, аларның икешәр кредиты бар (фатир өчен, машина өчен). Бу очракта аларны мохтаҗ дип әйтеп буламы?**

**Сезгә уңышлар теләп,**

**Салих Зиннәтов,**
**Зәй районы, Аксар авылы.**

**Сорауларга шәригать белгече Рәфыйк хәзрәт Миннәхмәтов җавап бирә:**

- Җаһилият вакытында гарәпләр балаларны уллыкка ала торган булганнар һәм ул бала үз улы хөкемендә саналган. Әмма ислам дине килгәч, бу тыелган, Аллаһы Тәгалә аңлаткан: кешенең үз каныннан, үз нәселеннән булмаган баласы аның улы, варисы булмый. Асрауга ятим балаларны алу тыелмаган, бу гөнаһ түгел, киресенчә, караучылары булмаса, саваплы эш. Асрауга алган ир кешегә, хөрмәт йөзеннән, "эти" дип, асрамага алган балага "улым, кызым" дип эндәшү дә шәригать буенча тыелмый. Мәгәр аңа фамилия бирү дә, отчество, ягъни асрауга алган атаның исемен бирү дә ярамый. Үз атасының исеме билгеле икән – шул исем-фамилия, әгәр анасыныкы гына билгеле икән (әйтик, әни кеше баласын тудыру йортында калдырып чыга, аның фамилиясе билгеле була бит) – анасының фамилиясе бирелә, ә асрауга алган атаныкы түгел! Төрле очрак була: мәсәлән, урамда калдырылган бала турында бер мәгълүмат та булмаска мөмкин. Асрауга алган гаилә документларда үз фамилиясен бирә икән, балага аның үзенеке түгеллеген кечкенәдән әйтү кирәк, моны яшерергә ярамый. "Атаң кем?" дигән сорауга бала үзенең чын әтисенең исемен әйтеп җавап бирергә тиеш. Ата-анасының кемлеге билгеле булмаганда да, бала дөреслекне сабый вакытыннан ук белеп үсәргә тиеш, моны яшерү харам санала. Еш кына, әйтмичә, яшереп калдыралар да, бала үсеп җиткәч, бик күп проблемалар барлыкка килә. Ул хакыйкатьне, үскәч, чит кеше авызыннан ишетсә, бик авыр кичерә. Өйдән чыгып киткән очраклар бар, судлашып йөргәннәр... Шуңа күрә, кабатлап әйтәм, балага дөреслекне кечкенәдән әйтү кирәк, ул моңа гадәтләнеп, өйрәнеп үсә. Мирас бүлү мәсьәләсендә, асрауга алынган бала чит кеше хөкемендә була, асраучының үз баласы кебек өлеш ала алмый. Асрауга алган ата кеше исә, теләсә, малының күпмедер өлешен үзе исән чагында ук үги улына бирә ала, яки аңа малының өчтән беренә хәтле васыять итә ала, бу шәригатькә каршы килми.

- Үз балаларыңа, оныкларыңа зәкәт, гошер бирү дөрес түгел. Ир – хатынга, хатын – иргә, әти-әниләргә, әби-бабайларга да зәкәт, гошер сәдакалары бирелми, гәрчә алар мохтаҗ булсалар да. Аларга болай да, зәкәттән башка да ярдәм итәләр бит инде. Фарыз булган сәдакаларны, бертуганыңнан башлап һәм ераграк туганнарга бирергә ярый.

## ӘДӘБИ СҮЗ

### Аллаһ кодрәте

Аллаһның өч сыйфаты бар:
Үзгәрешсез иҗат итү –
Юктан барлык ясап үтү,
Адәм җанын садә итү.

Икенчесе – халик итү:
Бер нәрсәдән башка нәрсә,
Йолдызларны һәм галәмне
Ясап кую, ихтар итү.

Өченчесе – тәгъбир итү
Бу хәрәкәт-галәмдәге.
Күк-җисемнәр катгыяны
Тәртип ясау галәмәте.

Җансыз туфрак – адәм итү.
Акыл, фикер һәм тел бирде.
Җан мәңгелек күккә борды,
Үлгән тәнне туфрак итте.

Җисемнәрне, әйберләрне,
Галәмнәрне хасил итте.
Җир- Кояшны тәкъдир итте –
Аллаһ бөек хөкемдардыр.

### Изге җомга көне

Җомга җитсә – җан бәйрәме,
Мең уй килеп бәйләнә.
Намаз укып, дога кылсаң,
Зур бәйрәмгә әйләнә.

Мең шаһиты көн-агымның
Йөзләргә сала чалым.
Тәңре хакы моңлы хәят,
Мөлдерәп тулган чагың.

Дөнья мәшәкатен куып,
Җан куенга сыена.
Караңгылык актыра да
Күзләр яшьтән сыгыла.

Дога тәнгә сихәт бирә,
Тәңре көннән яраткан.
Аллаһы безне бар иткән,
Яшә диеп җан аткан.

Дога укы, хәләл аша,
Җомгаларга баргала.
Ике дөнья рәхәте дә
Ахирәттә барлана.

**Альбина Авзалова,**
**Актаныш.**

*Юл язмасы*

# "Аллаһка таянып, сынмый калдым"

Ул һәркем белән ярты чакрымнан елмаеп күрешә, хәл-әхвәлен белешеп, ачык йөз белән исәнләшә. Китап укырга ярата икән, Нәҗибә ханымның шулай дипюе сүз җебен әдәби әсәрләргә, язучыларга бәйләп куйды. Җитмәсә, бер үк авторларны яратып укыйбыз икән. "Минем язмышым үзе дә китаптан ким түгел анысы", - дип сүз башлады ул, бервакыт кыска гына күрешүебездә.

— Үземнең тормышымны өч кисәккә бүлеп карыйм мин. Иремә кияүгә чыгып, аның белән яшәгән елларым, ирем үлгән чак, шуннан соң үткән гомерем — өчесе өч кешенеке кебек... Парлы тормышыбыз сынаулы башланды башлануы, беренче балабыз биш айлык чагында вафат булды. Әлләә прививка ярамады, ни сәбәп икәнен бер Аллаһ кына белә инде. Ул чактагы күз яшьләремнең ачылыгын сөйләп аңлата торган түгел. Шуннан соң бер-бер артлы өч бала алып кайттык. Инде түгәрәкләндек дигәндә, өебезгә кара кайгы килеп керде — аварияга очрап, ирем үлде. Төпчегебез тәпи генә киткән чак иде. Акылдан язудан шул балаларым гына саклап калгандыр... Төн җитсә, өйдә йоклаудан куркам, ишекләрне, капкаларны бикләп, кат-кат тикшереп керәм, ишек катына балта-пычак куеп йокларга ятам — гел кемдер килеп керер шикелле. Ир исән чакта ишек бикләнгәнме, юкмы — искә дә алганым булмады югыйсә, ә хәзер куркам... Шул куркуны балаларга да йоктырдым. Бервакыт кайтып киләм — олы улым беренче класста укый иде, мәктәптән кайткан да балакаем, коеп яуган яңгыр астында капка төбендә басып тора. "Әни, мин өйгә керергә куркам", — ди улым. Шул хәлдән соң әкренләп-әкренләп үземне кулга ала башладым, нык булырга тырыштым. Аллаһы Тәгаләдән сабырлык сорадым, догалар укып, намазга басып, шул сабырлыкка ирештем дә кебек. "Бу хәсрәтләр ни өчен бирелде икән?" — дип еш уйлана идем. Барысы да бер сынаудыр инде, күрәсең... Югыйсә, беркемгә дә, бернәрсәгә дә зыян салмаска тырышып яшим. Бер вакыйганы сөйлим әле үзеңә. Ирем үлгәч булды инде ул. Март башы иде. Беркөнне кич сыер савып утырам, өйдән улым йөгереп чыккан. "Әни, кухняда кап-кара елан йөри, суыткыч астына кереп киткәнен күрдем", — ди. Безнең авыл урманга якын, җәен ишегалдына еланнар төшкәли инде. Ә монда, урамда кар ятканда, каян килеп чыккандыр, кем белсен. Мин сыерны савып бетергән арада улым: "Әни, еланны тоттым, сумкага салып куйдым", — дип тагын йөгереп чыккан. "Ярар, мин әйтәм, бирәр кая илтеп ыргыт инде үзен", — дим.

Йокларга яттык. Күзгә йокы керми генә бит. Башыма әллә нинди уйлар килә. Ул елан да Аллаһы Тәгалә яраткан җан иясе бит. Урамга чыгарып ыргытырга куштым да кушуын... Анда бит салкын кыш, катып үлә бит инде ул анда дим. Безгә рәнҗеше төшсә? Түзмәдем, улымнан сорыйм: "Еланны кайда калдырганыңны хәтерлисеңме?" — дим. "Әйе, мин аны зират капкасы буенда башы белән карга тыгып калдырдым", — ди. Киендек тә киттек шунда. Чыннан да, улым ничек калдырса, кар өстендә ята теге елан. Алып кайттык, банкага салып, җилем капкач белән каплап куйдык. Бераздан еланыбыз боргаланып, капкачны эчтән төрткәли башлады. Без йоклагач, тәки төртеп чыга бит бу моны, дим. Инде банканы кат-кат целлофан пакетларга төреп, нык тып бәйләп куйган булдык, һава керсен өчен вак-вак тишекләр ясадык. Ул көнне йокыбыз йокы булмады, шул еланны саклап чыктык. Мин аны соңыннан эшкә алып барып, кызларга күрсәттем дә подвалга җибәрдек үзен. "Мин сиңа тимәдем, син дә миңа, минем балаларыма, нәселемә зыян салма", дия-дия җибәрдем.

Инде балаларым буй җиткерде, исән-сау яшәдек, аларны аякка бастырырга Аллаһ үзе көч бирде. Ничек кенә авыр булмасын, беркемгә кара коелмадым, якты йөз белән яшәргә тырыштым. Эштә җитәкчебез (ул мәрхүм инде, бу сүзләрем дога булып барып ирешсен үзенә) һәрчак әйтә иде: "Әнә, Америкада бар кеше безнең Нәҗибә кебек ачык йөзле булып, елмаеп яши", — ди торган иде... Ничек көч таптыммы? — Авыр минутларымда Коръән аятьләре укып, Аллаһка сыенып көч таптым мин, сынмый калырга шул ышаныч кына ярдәм итте...

**Айгөл Әхмәтгалиева.**

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

# “Һәр чорның үз әдәбе”



**Көнкүреш әдәбе — халыкның йөзен, холкын билгеләүче бер сыйфат. Кайчагында “ярый-ярамый”, “тиеш-тиеш түгел” кебек төшенчәләр арасында буталып та каласың. Кайбер сорауларга ислам дине күзлегеннән карап җавап эзләргә омтылуыбыз. Әңгәмәдәшем — Чаллының “Ак мәчет” имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Шәйхевәли.**

***— Рөстәм хәзрәт, кайберәүләр фикеренчә, кешеләрнең бер-берсенә “сез” дип мөрәҗәгать итүе дөрес түгел. “Аллаһы Тәгаләгә дә син дип дәшәбез, ни өчен әле аерым бер кешене сез дип зурларга тиешбез?” — дип бәхәс кузгалган мәлләргә тап булганым бар. Сезнеңчә, болай диючеләр ни дәрәҗәдә хаклы?***

— Татар халкында элек бер-береңә “сез” дип эндәшү гомердә дә булмаган. Олы кешегә дә: “Фәлән бабай, син мине гафу ит инде”, — дип эндәшкәннәр. Элек, әле без мәктәптә укыган елларда, укытучыларга да “син” ди торган идек. Иң олуг зат — Аллаһы Тәгалә, без аңа барыбыз да “син” дип мөрәҗәгать итәбез.

Һәр чорның — үз әдәбе. Әйтик, патша императоры вакытында ул үз фәрманын өченче заттан җиткерә торган булган: “Император галиҗәнапләре боера...” Совет чорында безнең халыкта түрәләргә “сез” дип дәшү гадәте килеп керә. Бүген инде кайберәүләргә шулай күплек санда мөрәҗәгать итү — хөрмәт күрсәтү билгесе буларак кабул ителә. Мин үзем кешегә “син” дип дәшүдән дә, “сез” диюдән дә зыян күрмим, гөнаһы юк дип саныйм.

***— Хәзер хатын-кызлар арасында да, ир-атлар арасында да спорт белән шөгыльләнүчеләр бик күп. Кызганыч, шәһәрдә мөселманнар өчен аерым бассейн юк. Хатын-кызлар, шәригатьчә киенгән хәлдә, ир-атлар янәшәсендә су коена аламы, әллә бу тыеламы?***

— Шәригатьчә киенсә дә, ир-атлар белән бергә су коенырга ярамый! Теләгән очракта, мөселманнар бергә җыелып, бассейнның аерым сәгатьләрен үзләре өчен генә сатып алу мөмкинлеге бардыр дип уйлыйм. Бу очракта да хатын-кызлар, гәрчә үзләре генә булсалар да, шәригатьчә киенеп коенырга тиеш.

***— Гасырлар дәвамында халыкның чабуына тагылып килгән төрле хорафатлар бар: тупсага утырма — үсми каласың, ашаганда аягыңны селкемә — шайтан чакырасың; юлыңа кара мәче чыкса — юлың уңмас...***

— Хорафатларның кайберләре тәрбияви максаттан да килеп чыккан бит. Әйтик, бала тупсага утыра икән, аның ишеккә кысылуы, гарипләнүе бар. Өстәл янында аяк селкеп утырма дип әйтү — әдәплелеккә өйрәтергә теләү. Тик халык кайчагында шуның ише сәбәпләргә бәйләп, диннән дә чыгып китә: янәсе, каршыңа буш чиләк белән очрасалар яки кара мәче чыкса — юлың уңмый... Ә бит бар гамәлләребезнең хуҗасы — Аллаһы Тәгалә, менә шуны истән чыгармаска кирәк. Теләсә нәрсә дип юрап утырганчы, барысы да яхшы булсын дип, Аллаһтан сорау хәерле.

***— Кайберәүләр, башларына хәсрәт килсә, “Аллаһы Тәгалә ни өчен шундый сынау бирде?” дип өзгәләнә. Сынмас-сыгылмас өчен каян көч табарга белми. Андыйларга нинди киңәш бирер идегез?***

— Аллаһы Тәгалә яраткан бәндәсенә сынауларны күп бирә. Аларны сабырлык белән, Аллаһка таянып күтәрә белергә кирәк. Бервакыт яныма бер ханым килгән иде. Авариядә ире, ике баласы үлгән. “Әле дә мин ислам динендә, алайса, бу кайгыларны ничек күтәргән булыр идем? — ди.

Без, гадәттә, кешегә озын гомер теләргә яратабыз. Тик гомер озынрак булган саен, сынаулар да күбәя шул. Үзләре озак яшәп, бер-бер артлы балаларын җирләгән карт кешеләр бар — алар өчен озын гомер бәхет микән? Картлык көнендә авызыңа суны балаларың каптырамы, әллә чит кеше кулына каласыңмы? Безнең күршедә күпне күргән Харис бабай бар иде, шуның минем бабайга: “И Шәйхевәли, кешене бер дә каргыйсы юк икән, озын гомерле бул дисәң дә җитә икән”, — дигәнен һич онытмыйм. Менә шуларны уйлап, теләкне дә дөрес итеп тели белергә кирәк...

**Әңгәмәдәш – Айгөл Әхмәтгалиева.**

# Локман Хәким нәсыйхәте

*Ягъкуб галәйһиссәлам үлем фәрештәсе белән дус була. Бервакыт үлем фәрештәсе аңа кунакка килә. Ягъкуб галәйһиссәлам сорый: “Йә үлем фәрештәсе, син кунакка килдеңме, әллә җанымны алыргамы?” “Зиярәт кылырга килдем”, - ди үлем фәрештәсе. Ягъкуб галәйһиссәлам әйтә: “Минем сиңа бер үтенечем бар. Син минем җанымны алырга килер алдыннан кисәтеп куй әле”. ”Ярар, хуш, мин сиңа алдан ике яки өч илчемне җибәрермен”. Ягъкуб галәйһиссәламнең әҗәле җиткәч, аңа үлем фәрештәсе килә. Ул сорый: “Син мине зиярәт итәргә килдеңме? Әллә җанымны алыргамы?” “Җаныңны алырга”. “Син бит ике яки өч илче җибәрермен, дигән идең”. “Мин шулай иттем дә. Кара чәчләреңә чаллык җибәрдем. Куәтле тәнеңә зәгыйфьлек җибәрдем. Туры умырткаңа кәкрелек җибәрдем. Йә Ягъкуб, болар минем кешеләргә килүче илчеләрем инде”, - ди үлем фәрештәсе.*


***Балалар өчен***

*Алинә Фәсхиева*

*“Дөнья мәчетләре буйлап” цикльннан*


## *Әл-Мәрҗани мәчете*

*(Казан шәһәре)*



Ак ташлы иске диварлар,
Ямь-яшелдән түбәсе.
Матурраклар бар, әлбәттә,
Ә бу — иң кадерлесе.
Мөселман җәмгыятенең
Тарихы яши анда.
Иң беренче бу таш мәчет
Шәех Шиһабетдинның да
Мирасын саклап бара!

*(Ф.Мөслимова тәрҗемәсе)*



**ТӨСЛЕ КАЛӘМ БЕЛӘН БУЯГЫЗ**

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, яки башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды: график буенча 29 гыйнвар 16 сәг. фактта 29 гыйнвар 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**